**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**КАРАР**

« 19 » сентябрь 2025 ел Яр Чаллы ш. № 3118

2025елга гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының чик күләмнәрен билгеләү турында

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Татарстан Республикасы Дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы, гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының чик күләмнәрен билгеләү методикасы, «Татарстан Республикасы бәяләүчеләр берләшмәсе» коммерциясез партнерлыгының 2025 елның 27 августындагы 265 номерлы «Бәяләр диапазонын билгеләү турында» бәяләмәсе нигезендә Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2025 елга гражданнарны аз керемлеләр дип тану турында карар кабул итү өчен түбәндәге чик күләмнәрне билгеләргә:

1.1. гаилә әгъзалары (ялгыз яшәүче граждан) милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының чиге:

- ялгыз яшәүче кеше өчен – 1 262 052 сум;
- ике кешедән торган гаилә өчен – 2 524 10 сум;
- өч кешедән торган гаилә өчен – 3 786 156 сум;
- дүрт кешедән торган гаилә өчен – 5 048 208 сум;
- биш кешедән торган гаилә өчен – 6 310 260 сум;
- алты кешедән торган гаилә өчен – 7 572 312 сум;
– җиде кешедән торган гаилә өчен – 8 834 364 сум;
- сигез кешедән торган гаилә өчен – 10 096 416 сум;

1.2. гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керем күләме:

- ялгыз яшәүче граждан өчен – 35 342 сум 39 тиен;
– ике кешедән торган гаилә өчен – 35 342 сум 41 тиен;
- өч һәм аннан артык кешедән торган гаилә өчен – 35 342 сум 41 тиен.

2. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетына әлеге карарда күрсәтелгән максималь чик күрсәткечләрне торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ гражданнарны исәпкә алганда кулланырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) яки Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе К.Р. Нәҗмиев